РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41


РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 69 2021 елның 18 ноябре

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2006 елның 13 октябрендәге 48 номерлы «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлау оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль законның 28 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 2021 елның 1 июлендәге 289-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2021 елның 11 июнендәге 191-ФЗ номерлы Федераль закон, Түбән Кама муниципаль районы Уставы нигезендә Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2006 елның 13 октябрендәге 48 номерлы «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлау оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемендәге «һәм үткәрү» сүзләренә «иҗтимагый фикер алышу һәм» сүзләрен өстәргә;

карарга кушымтада:

4.4 пунктта түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Иҗтимагый фикер алышу яисә гавами тыңлауга чыгарылучы муниципаль хокукый акт проекты, иҗтимагый фикер алышулар һәм гавами тыңлаулар уздырылган көнгә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.»;

4 нче бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 4.5 пунктын өстәргә:

«4.5. Иҗтимагый фикер алышу һәм гавами тыңлау үткәрү турындагы карарны, иҗтимагый фикер алышуга яисә гавами тыңлауга чыгарылучы тиешле муниципаль хокукый акт проектын, иҗтимагый фикер алышуга яисә гавами тыңлау нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне, бәяләмәнең дәлилләнгән нигезләмәсен, муниципаль берәмлек халкына муниципаль хокукый акт проекты буенча үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен бирү мөмкинлеген тәэмин итүне дә кертеп, урнаштыру өчен, шулай ук муниципаль берәмлек халкының гавами тыңлауларда катнашуы өчен "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы" федераль дәүләт мәгълүмат системасы

кулланылырга мөмкин, аны куллану тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.»;

5.6 пунктка « шул исәптән Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайты аша» сүзләрен өстәргә;

5.6.2 пунктының 3 пунктчасында «язма рәвештә» сүзләреннән соң «яисә электрон документ формасында» сүзләрен өстәргә;

7.4 пунктының беренче абзацында «рәсми бастырып чыгару» сүзләреннән соң, «шул исәптән, бәяләмәнең дәлилләнгән нигезләмәсен дә кертеп, Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында,» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы,
район Башлыгы урынбасары

ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН

А.В.Умников